**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 25 маендагы 1797 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 октябрендәге 3413 номерлы «"2026-2028 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү" муниципаль программасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2026-2028 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү» муниципаль программасының финанс күрсәткечләрен 2026 елның бюджет гаризасына туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 октябрендәге 3413 номерлы «"2026-2028 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү" муниципаль программасын раслау турында»гы карары белән расланган «2026-2028 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү» муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. программа паспортында «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме | Финанслауның гомуми күләме 62 486,44 мең сум тәшкил итә. Программаны финанслау күләмнәре фаразлау рәвешендә бирелә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре бюджеты проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Ел | Акча күләме, мең сумнарда | | |
| | | барлыгы | Казан шәһәре муниципаль бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар |
| | 2026 | 22 432,64 | 22 432,64 | - |
| | 2027 | 20 011,90 | 20 011,90 | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2028 | 20 041,90 | 20 041,90 | - |
| | Барлыгы | 62 486,44 | 62 486,44 | -» |

1.2. «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» дигән III бүлектә таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Чаралар** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** |
|---|---|---|---|
| «1 нче төп чара.<br>Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенең тышкы реклама өлкәсендәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеген башкаруны тәэмин итү (аппаратны агымдагы карап тоту), мең сумнарда | 21 970,64 | 19 549,90 | 19 579,90 |
| 2 нче төп чара.<br>Законсыз урнаштырыла торган реклама корылмаларын оператив рәвештә мәҗбүри сүтүне тәэмин итү, мең сумнарда | 462,00 | 462,00 | 462,00 |
| Барлыгы, мең сумнарда | 22 432,64 | 20 011,90 | 20 041,90» |

1.3. Программаның 1 номерлы кушымтасын әлеге карар кушымтасы нигезендә редакцияләп бирергә;

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 25 маендагы
1797 номерлы карарына
кушымта

**«2026-2028 елларда Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсен үстерү» муниципаль программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм муниципаль программа чаралары буенча финанслау**

| Төп чараларның атамалары | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Финанслау, мең сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Төп ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| **Максат: Казан шәһәрендә тышкы реклама базарының инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыру** | | | | | | | | | | |
| **1 нче бурыч: шәһәр инфраструктурасының социаль әһәмияткә ия объектларында реклама чыганаклары санын арттыру.** | | | | | | | | | | |
| 1.1. Шәһәр инфраструктурасының социаль әһәмияткә ия объектларында реклама корылмаларын | | | **Шәһәр инфраструктурасының социаль әһәмияткә ия объектларында реклама корылмаларын урнаштыруга рөхсәтләр бирү** | **423** | **450** | **500** | **550** | **-** | **-** | **-** |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| урнаштыруга рөхсәтләр бирү | | | | | | | | | | |
| 2.1 нче төп чара. Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенең тышкы реклама өлкәсендәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне башкару эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү (аппаратны агымдагы карап тоту) | Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе | 2026-2028 еллар | **Тышкы реклама идарәсе эшчәнлеге һәм тышкы реклама өлкәсендәге функцияләрне һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча мәгълүмат хисабына Казан шәһәре бюджетының кереме, мең сумнарда** | **378297** | **420000** | **420000** | **420000** | **21 970,64** | **19549,9** | **19579,9** |
| 2.2. Шәһәр инфраструктурасының социаль әһәмияттәге объектларында реклама корылмаларын урнаштыруга нәтиҗәле | Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе | 2026-2028 еллар | **Ел ахырына инфраструктураның таләпләрне бозып файдаланыла торган социаль әһәмиятле объектларындагы конструкцияләр өлеше, реклама корылмаларының гомуми саныннан %** | **4** | **<3,5** | **<3** | **<2,5** | **-** | **-** | **-** |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| контроль гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | |
| 2.4 нче төп чара. Законсыз урнаштырыла торган реклама корылмаларын оператив рәвештә мәҗбүри сүтүне тәэмин итү | Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе | 2026-2028 еллар | **Ел ахырына Казан шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларының өлеше, реклама корылмаларының гомуми саныннан %** | **<0,14** | **<0,13** | **<0,13** | **<0,12** | 462,0 | 462,0 | 462,0 |
| **Программа буенча барлыгы: 62 486,44 мең сум** | | | | | | | | 22432,64 | 20011,9 | 20041,9 |